**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в статьи 2 и $2^1$ Закона Республики Татарстан «О реализации государственной политики в области содействия занятости населения в Республике Татарстан» и Закон Республики Татарстан «О квотировании и резервировании рабочих мест для инвалидов и граждан, особо нуждающихся в социальной защите»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
25 октября 2021 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 19 июня 2006 года № 39-ЗРТ «О реализации государственной политики в области содействия занятости населения в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2006, № 6 (I часть); 2007, № 4; 2011, № 8 (I часть); 2012, № 12 (I часть); 2014, № 6 (II часть), № 12 (II часть); 2015, № 5, № 10 (I часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 27 (часть I); 2018, № 1 (часть I), № 92 (часть I); 2020, № 1 (часть I), № 51 (часть I) следующие изменения:

1) пункты 2 и 4 статьи 2 признать утратившими силу;

2) в статье $2^1$:
а) в части 3:
в пункте 1:
абзацы второй – четвертый изложить в следующей редакции:
«порядок, условия предоставления и размер единовременной финансовой помощи при государственной регистрации в качестве индивидуального предпринимателя, государственной регистрации создаваемого юридического лица, государственной регистрации крестьянского (фермерского) хозяйства, постановке на учет физического лица в качестве налогоплательщика налога

на профессиональный доход гражданам, признанным в установленном порядке безработными, и гражданам, признанным в установленном порядке безработными, прошедшим профессиональное обучение или получившим дополнительное профессиональное образование по направлению органов службы занятости;

порядок и условия направления органами службы занятости женщин в период отпуска по уходу за ребенком до достижения им возраста трех лет, незанятых граждан, которым в соответствии с законодательством Российской Федерации назначена страховая пенсия по старости и которые стремятся возобновить трудовую деятельность, для прохождения профессионального обучения или получения дополнительного профессионального образования;

порядок предоставления финансовой поддержки безработным гражданам и женщинам в период отпуска по уходу за ребенком до достижения им возраста трех лет, а также незанятым гражданам, которым в соответствии с законодательством Российской Федерации назначена страховая пенсия по старости и которые стремятся возобновить трудовую деятельность, направленным органами службы занятости для прохождения профессионального обучения или получения дополнительного профессионального образования в другую местность, а также размеры указанной финансовой поддержки;»;

дополнить абзацем следующего содержания:

«порядок и условия взаимодействия органов службы занятости с работодателями (по вопросам организации рабочих мест, включая специальные рабочие места для трудоустройства инвалидов, подбора инвалидов для замещения свободных рабочих мест, вакантных должностей) и организациями, осуществляющими образовательную деятельность по образовательным программам профессионального обучения и (или) дополнительным профессиональным программам для граждан из числа инвалидов, в целях замещения свободных рабочих мест, вакантных должностей, в том числе в рамках установленной квоты для приема на работу инвалидов;»;

пункт 2 изложить в следующей редакции:

«2) разработка с учетом мнения Республиканской трехсторонней комиссии по регулированию социально-трудовых отношений региональных программ, предусматривающих мероприятия по содействию занятости населения, включая программы содействия занятости граждан, находящихся под риском увольнения, а также граждан, особо нуждающихся в социальной защите и испытывающих трудности в поиске работы, в том числе по организации сопровождения при содействии в трудоустройстве и занятости инвалидов, и реализация таких программ;»;

пункт 3 дополнить словами «, включая меры по содействию в трудоустройстве и занятости инвалидов»;

б) в части 4:

пункт 4 изложить в следующей редакции:

«4) осуществление в соответствии с положением, утверждаемым Кабинетом Министров Республики Татарстан, регионального государственного контроля (надзора) за приемом на работу инвалидов в пределах установленной квоты;»;

дополнить пунктом $4^1$ следующего содержания:

«$4^1$) осуществление в отношении государственных учреждений службы занятости населения контроля за регистрацией инвалидов в качестве безработных и обеспечением государственных гарантий в области содействия занятости населения, за исключением полномочий, предусмотренных подпунктом 11 пункта 3 статьи 7 Закона Российской Федерации от 19 апреля 1991 года № 1032-1 «О занятости населения в Российской Федерации»;»;

в пункте 6:

абзац второй изложить в следующей редакции:

«содействие гражданам в поиске подходящей работы;»;

абзац седьмой изложить в следующей редакции:

«организация профессионального обучения и дополнительного профессионального образования безработных граждан, включая обучение в другой местности;»;

абзац восьмой признать утратившим силу;

в абзаце девятом слова «граждан в возрасте от 18 до 20 лет, имеющих среднее профессиональное образование и ищущих работу впервые» заменить словами «граждан в возрасте от 18 до 25 лет, имеющих среднее профессиональное образование или высшее образование и ищущих работу в течение года с даты выдачи им документа об образовании и о квалификации»;

абзац одиннадцатый изложить в следующей редакции:

«содействие началу осуществления предпринимательской деятельности безработных граждан, включая оказание гражданам, признанным в установленном порядке безработными, и гражданам, признанным в установленном порядке безработными и прошедшим профессиональное обучение или получившим дополнительное профессиональное образование по направлению органов службы занятости, единовременной финансовой помощи при государственной регистрации в качестве индивидуального предпринимателя, государственной регистрации создаваемого юридического лица, государственной регистрации крестьянского (фермерского) хозяйства, постановке на учет физического лица в качестве налогоплательщика налога на профессиональный доход;»;

дополнить абзацем следующего содержания:

«содействие работодателям в подборе необходимых работников;»;

пункт 7 изложить в следующей редакции:

«7) организация и проведение специальных мероприятий по профилированию граждан, зарегистрированных в целях поиска подходящей работы (распределение указанных граждан на группы в зависимости от сферы их предыдущей профессиональной деятельности, пола, возраста и других социально-демографических характеристик, а также статуса на рынке труда, потенциала трудоустройства и мотивации к трудоустройству), а также профилированию работодателей (распределение работодателей на группы в зависимости от организационно-правовой формы, вида экономической деятельности, финансово-экономического положения, условий труда, уровня заработной платы и других характеристик) в целях оказания указанным гражданам и работодателям

эффективной помощи при предоставлении государственных услуг в области содействия занятости с учетом складывающейся ситуации на рынке труда;»;

дополнить пунктом $10^{9}$ следующего содержания:

«$10^{9}$) организация проведения оплачиваемых общественных работ;»;

в) часть 6 признать утратившей силу;

г) дополнить частями 7 – 9 следующего содержания:

«7. Предметом регионального государственного контроля (надзора) за приемом на работу инвалидов в пределах установленной квоты является соблюдение работодателями обязательных требований в области квотирования рабочих мест, установленных нормативными правовыми актами Российской Федерации и нормативными правовыми актами субъектов Российской Федерации.

8. Организация и осуществление регионального государственного контроля (надзора) за приемом на работу инвалидов в пределах установленной квоты регулируются Федеральным законом от 31 июля 2020 года № 248-ФЗ «О государственном контроле (надзоре) и муниципальном контроле в Российской Федерации».

9. Органы государственной власти Республики Татарстан вправе организовывать взаимодействие с иными организациями при реализации полномочий в области содействия занятости населения.».

**Статья 2**

Внести в Закон Республики Татарстан от 24 июля 2006 года № 60-ЗРТ «О квотировании и резервировании рабочих мест для инвалидов и граждан, особо нуждающихся в социальной защите» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2006, № 7 (I часть); 2012, № 7 (I часть); 2013, № 7; 2014, № 6 (II часть), № 12 (II часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2019, № 2 (часть I) следующие изменения:

1) абзац девятый пункта 3 статьи 2 изложить в следующей редакции:

«граждане в возрасте от 18 до 25 лет, имеющие среднее профессиональное образование или высшее образование и ищущие работу в течение года с даты выдачи им документа об образовании и о квалификации;»;

2) в статье 3:

а) дополнить частями $1^{1}$ и $1^{2}$ следующего содержания:

«$1^{1}$. Численность работников для целей исчисления квоты для приема на работу инвалидов определяется исходя из среднесписочной численности работников без учета работников филиалов и представительств работодателя, расположенных в других субъектах Российской Федерации.

$1^{2}$. Находящимся на территории Республики Татарстан филиалам и представительствам работодателя, расположенного в другом субъекте Российской Федерации, квота для приема на работу инвалидов устанавливается в соответствии с настоящим Законом исходя из среднесписочной численности работников таких филиалов и представительств работодателя.»;

б) в части 5 слова «результатам аттестации рабочих мест по условиям труда или» исключить;

в) дополнить частями 11 и 12 следующего содержания:

«11. Квота для приема на работу инвалидов считается выполненной работодателем в случае оформления в установленном порядке трудовых отношений с инвалидами в рамках исполнения работодателем обязанности по трудоустройству инвалидов в соответствии с установленной квотой.

12. Оформление работодателем в установленном порядке трудовых отношений с инвалидом на любое рабочее место считается выполнением квоты для приема на работу инвалидов в случаях и порядке, которые установлены Правительством Российской Федерации.»;

3) пункт 3 части 2 статьи 6 после слов «программой реабилитации» дополнить словами «или абилитации».

**Статья 3**

1. Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования, за исключением положений, для которых настоящей статьей установлены иные сроки вступления их в силу.

2. Абзацы семнадцатый и восемнадцатый подпункта «б» пункта 2 статьи 1 настоящего Закона вступают в силу с 1 января 2022 года.

3. Пункт 2 статьи 2 настоящего Закона вступает в силу с 1 марта 2022 года.

Президент
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
03 ноября 2021 года
№ 84-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм $2^1$ статьяларына һәм «Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары квоталау һәм резервлау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 25 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» 2006 елның 19 июнендәге 39-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 6 (I өлеш); 2007, № 4; 2011, № 8 (I өлеш); 2012, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 5, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 51 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 2 һәм 4 пунктларын үз көчләрен югалткан дип танырга;

2) $2^1$ статьяда:
а) 3 өлештә:
1 пунктта:
икенче – дүртенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«билгеләнгән тәртиптә эшсезләр дип танылган гражданнарга һәм билгеләнгән тәртиптә эшсезләр дип танылган һәм халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча һөнәри уку узган яисә өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга индивидуаль эшкуар буларак дәүләт теркәвенә куелганда, төзелә торган юридик зат дәүләт теркәвенә куелганда, крестьян (фермер) хуҗалыгы дәүләт теркәвенә куелганда, физик зат һөнәри керемгә салымның салым түләүчесе буларак

исәпкә куелганда бер мәртәбә финанс ярдәме күрсәтү тәртибен, шартларын һәм күләмен;

өч яшькә кадәрге бала карау ялында булу чорында хатын-кызларны, Россия Федерациясе законнары нигезендә картлык буенча иминият пенсиясе билгеләнгән һәм хезмәт эшчәнлеген торгызырга омтылган эш белән тәэмин ителмәгән гражданнарны халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары тарафыннан һөнәри уку узуга яисә өстәмә һөнәри белем алуга юллау тәртибен һәм шартларын;

һөнәри уку узу яисә өстәмә һөнәри белем алу өчен халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары тарафыннан башка җиргә юлланган эшсез гражданнарга һәм өч яшькә кадәрге бала карау ялында булу чорында хатын-кызларга, шулай ук Россия Федерациясе законнары нигезендә картлык буенча иминият пенсиясе билгеләнгән һәм хезмәт эшчәнлеген торгызырга омтылган эш белән тәэмин ителмәгән гражданнарга финанс ярдәме күрсәтү тәртибен, шулай ук күрсәтелгән финанс ярдәменең күләмнәрен;»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«буш эш урыннарын, вакантлы вазыйфаларны биләү максатларында, шул исәптән инвалидларны эшкә алу өчен билгеләнгән квота кысаларында, эш белән тәэмин итү хезмәте органнарының эш бирүчеләр (эш урыннарын, инвалидларны эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннарын да кертеп, оештыру, буш эш урыннарын, вакантлы вазыйфаларны биләү өчен инвалидларны сайлап алу мәсьәләләре буенча) һәм инвалидлар арасыннан булган гражданнар өчен һөнәри белем бирүнең уку-укыту программалары буенча һәм (яисә) өстәмә һөнәри программалар буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар белән үзара хезмәттәшлек итү тәртибен һәм шартларын;»;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) эштән җибәрү куркынычы янаган гражданнарны, шулай ук социаль яклауга аеруча мохтаҗ һәм эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче гражданнарны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү программаларын да кертеп, халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү, шул исәптән инвалидларны эшкә урнаштыруга һәм эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәткәндә булышып торуны оештыру чараларын күздә тота торган региональ программаларны, Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республика өчьяклы комиссиясе фикерен исәпкә алып, эшләү һәм мондый программаларны гамәлгә ашыру;»;

3 пунктта «өстәмә чаралар» сүзләреннән соң «, шул исәптән инвалидларны эшкә урнаштыруга һәм эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү чараларын кертеп,» сүзләрен өстәргә;

б) 4 өлештә:

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган нигезләмәгә таянып, билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру;»;

түбәндәге эчтәлекле $4^1$ пункт өстәргә:

«$4^1$) халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең дәүләт учреждениеләренә карата инвалидларны эшсезләр буларак теркәүгә һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә

ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт гарантияләрен тәэмин итүгә контрольне гамәлгә ашыру, моңа «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 7 статьясындагы 3 пунктының 11 пунктчасында каралган вәкаләтләр керми;»;

6 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«яраклы эш эзләүдә гражданнарга ярдәм итү;»;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«башка җирдә укытуны да кертеп, эшсез гражданнарны һөнәри укытуны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру;»;

сигезенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

тугызынчы абзацта «урта һөнәри белеме булган һәм беренче мәртәбә эш эзләүче 18 яшьтән 20 яшькә кадәрге» сүзләрен «урта һөнәри белеме яисә югары белеме булган һәм белеме турында һәм квалификация турында үзенә документ бирелгән датадан башлап бер ел дәвамында эш эзләүче 18 яшьтән 25 яшькә кадәрге гражданнар» сүзләренә алмаштырырга;

унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«билгеләнгән тәртиптә эшсезләр дип танылган гражданнарга, билгеләнгән тәртиптә эшсезләр дип танылган һәм халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча һөнәри уку узган яисә өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга индивидуаль эшкуар буларак дәүләт теркәвенә куелганда, төзелә торган юридик зат дәүләт теркәвенә куелганда, крестьян (фермер) хуҗалыгы дәүләт теркәвенә куелганда, физик зат һөнәри керемгә салымның салым түләүчесе буларак исәпкә куелганда бер мәртәбә финанс ярдәме күрсәтүне кертеп, эшсез гражданнарның эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлавына булышу;»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда эш бирүчеләргә булышу;»;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәткәндә, хезмәт базарында барлыкка килә торган вәзгыятьне исәпкә алып, яраклы эш эзләү максатларында теркәлгән гражданнарга һәм эш бирүчеләргә нәтиҗәле ярдәм итү максатларында, әлеге гражданнарны профильләштерү (күрсәтелгән гражданнарны аларның элеккеге һөнәри эшчәнлеге өлкәсенә, җенесенә, яшенә һәм башка социаль-демографик характеристикаларына, шулай ук хезмәт базарындагы статусына, эшкә урнашу потенциалына һәм эшкә урнашуга мотивациясенә бәйле рәвештә төркемнәргә бүлү), шулай ук эш бирүчеләрне профильләштерү (эш бирүчеләрне оештыру-хокукый рәвешләренә, икътисадый эшчәнлек төренә, финанс-икътисадый торышына, хезмәт шартларына, хезмәт хакы дәрәҗәсенә һәм башка характеристикаларга бәйле рәвештә төркемнәргә бүлү) буенча махсус чаралар оештыру һәм үткәрү;»;

түбәндәге эчтәлекле $10^9$ пункт өстәргә:

«$10^9$) түләүле җәмәгать эшләре башкаруны оештыру;»;

в) 6 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

г) түбәндәге эчтәлекле 7 – 9 өлешләр өстәргә:

«7. Билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга региональ дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) предметы эш урыннарын квоталау өлкәсендә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында һәм Россия Федерациясе субъектлары норматив хокукый актларында билгеләнгән мәҗбүри таләпләрнең эш бирүчеләр тарафыннан үтәлешеннән гыйбарәт.

8. Билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыру «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон белән җайга салына.

9. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда, башка оешмалар белән үзара хезмәттәшлек итүне оештырырга хокуклы.».

**2 статья**

«Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары квоталау һәм резервлау турында» 2006 елның 24 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 7 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 7; 2014, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 2 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 3 пунктындагы тугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«урта һөнәри белеме яисә югары белеме булган һәм белеме турында һәм квалификация турында үзенә документ бирелгән датадан башлап бер ел дәвамында эш эзләүче 18 яшьтән 25 яшькә кадәрге гражданнар;»;

2) 3 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ һәм $1^2$ өлешләр өстәргә:

«$1^1$. Инвалидларны эшкә алу өчен квота исәпләп чыгару максатларында хезмәткәрләрнең саны, эш бирүченең Россия Федерациясенең башка субъектларында урнашкан филиаллары һәм вәкиллекләре хезмәткәрләрен исәпкә алмыйча, хезмәткәрләрнең исемлектәге уртача саныннан чыгып билгеләнә.

$1^2$. Россия Федерациясенең башка субъектларында урнашкан эш бирүченең Татарстан Республикасы территориясендәге филиалларына һәм вәкиллекләренә инвалидларны эшкә алу өчен квота, эш бирүченең мондый филиаллары һәм вәкиллекләре хезмәткәрләренең исемлектәге уртача саныннан чыгып, әлеге Закон нигезендә билгеләнә.»;

б) 5 өлештә «хезмәт шартлары буенча эш урыннарына аттестация үткәрү яисә» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле 11 һәм 12 өлешләр өстәргә:

«11. Эш бирүче билгеләнгән квота нигезендә инвалидларны эшкә урнаштыру бурычын үтәү кысаларында инвалидлар белән хезмәт мөнәсәбәтләре билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән очракта, инвалидларны эшкә алу өчен квота эш бирүче тарафыннан башкарылган дип санала.

12. Эш бирүченең теләсә нинди эш урынына инвалид белән хезмәт мөнәсәбәтләрен билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерүе Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә инвалидларны эшкә алу өчен квотаның үтәлүе дип санала.»;

3) 6 статьяның 2 өлешендәге 3 пунктында «реабилитацияләүнең» сүзеннән соң «яисә абилитацияләүнең» сүзләрен өстәргә.

**3 статья**

1. Әлеге Закон, бу статьяда үз көченә керүнең бүтән сроклары билгеләнгән нигезләмәләреннән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пунктының «б» пунктчасындагы унҗиденче һәм унсигезенче абзацлар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге Законның 2 статьясындагы 2 пункты 2022 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 03 ноябрь
№ 84-ТРЗ